| | |
|---|---|
| РУКОВОДИТЕЛЬ ИСПОЛНИТЕЛЬНОГО<br>КОМИТЕТА БУГУЛЬМИНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БӨГЕЛМӘ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ БАШКАРМА<br>КОМИТЕТЫ ҖИТӘКЧЕСЕ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 13 октябрь г.Бугульма № 1115

**Бөгелмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең “Гражданинга социаль найм килешүе буенча муниципаль милектә булган торак бина бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында” 2016 елның 12 апреленнән №405 карарына үзгәрешләр кертү турында**

"Россия Федерациясенең аерым закон актларына мохтаҗлык принцибын үтәү һәм ихтыяҗ критерийларын куллану бурычларыннан чыгып социаль ярдәм чараларын бирүне исәпкә алу һәм камилләштерү өлешендә үзгәрешләр кертү турында" 2015 елның 29 декабрендәге 388 номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында Башкарма комитет карар бирә:

1. Социаль тәэмин итүнең бердәм дәүләт мәгълүмат системасы (алга таба-ЕГИССО) федераль дәүләт мәгълүмат системасы ярдәмендә торак урыннарына мохтаҗ гражданнарның аерым категорияләрен исәпкә кую буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентының 1 бүлегендәге 1.3.3 пунктына үзгәрешләр кертергә.
2. Торак урыннарына мохтаҗ гражданнарның аерым категорияләрен исәпкә кую буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентының 1 бүлегендәге 1.4 пунктына үзгәрешләр кертергә, аның түбәндәге эчтәлекле тексты белән тулыландырырга: "2015 елның 29 декабрендәге № 388 Федераль закон белән "Россия Федерациясенең аерым закон актларына мохтаҗлык принцибын үтәү һәм ихтыяҗ критерийларын куллану бурычларыннан чыгып социаль ярдәм чараларын бирүне исәпкә алу һәм камилләштерү өлешендә үзгәрешләр кертү турында".
3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "Торак урыннарына мохтаҗ гражданнарның аерым категорияләрен исәпкә кую буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентының 1 бүлеген 1.6 пункты белән тулыландырып, үзгәрешләр кертү хакында" 2006 ел, 30 декабрь, 641 нче карары. 1.6. Федераль закон нигезендә

социаль ярдәм чаралары күрсәтүче органнар Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә һәм күләмдә ЕГИССО куллану юлы белән күрсәтелгән социаль ярдәм чараларын күрсәтү турында мәгълүмат бирүне тәэмин итә.

Аерым категория гражданнарга социаль ярдәм чаралары турында мәгълүмат ЕГИССО тарафыннан Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм күләмдә ЕГИССО операторы тарафыннан билгеләнгән форматларга туры китереп алынырга мөмкин

4. Әлеге карарны тормышка ашыруда контрольне Башкарма комитет җитәкчесенең икътисад үсеше сораулары буенча урынбасары М.Р. Болгаковка йөкләргә.

А.Р. Галиуллин